**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы җирлеге Советы**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Совет Старотатарско-Адамского сельского поселения Аксубаевского муниципального района**

**423055 Республика Татарстан Аксубаевский район с. Старый Татарский Адам ул. Центральная дом 20**

Тел. (8-84344-4-35-84) ОГРН 1021605359610,
ОКПО 27839564, ИНН/КПП 1603000965/160301001
E-mail*: Stadam.Aks@tatar.ru*

---

КАРАР

№38 31.05.2022 ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге Советының «Аксубай муниципаль районы « Иске Татар Әдәмсуы авыл җйрлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2020 елның 21 маендагы 105 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге Советының «Аксубай муниципаль районы « Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2020 елның 21 маендагы 105 номерлы карарына 1 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 2.3.пунктның 3 пунктчасында «оешмалар)» сүзеннән соң «санлы финанс активлары, санлы валюта» сүзләрен өстәргә;
1.2. 2.4.пунктның 3 пунктчасында «оешмалар)» сүзеннән соң «санлы финанс активлары, санлы валюта» сүзләрен өстәргә.

2. «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Нигезләмәнең кушымтасында «оешмалар» сүзләреннән соң «санлы финанс активлары, санлы валюта» сүзләрен өстәргә.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo/tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге Советы рәисе Э.М.Хуснуллина